**ГЛАВА ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«20» март 2024 ел № 2

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 24.10.2023 №1 , «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 27.10.2023 №2 гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 №1, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымнарын кертү турында» 27.10.2023 №2 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча, Шахмай авылы, Үзәк урамы, 45 йорт адресы буенча урнашкан Шахмай авыл мәдәният йорты бинасында 2024 елның 31 мартында 10.00 сәгатькә билгеләргә.

2. . Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 27.10.2023 №2, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авыл җирлегендә 2024 елда гражданнарның үзара салым кертүе турында» 27.10.2023 №1 гражданнар җыены карарларына түбәндәге редакциядәге үзгәрешләр кертергә ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (таш белән капланган авыл юлларын чокырлы ремонтлау, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү, кышкы чорда юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), яз һәм көз айларында юлларны грейдировкалау (ягулык-майлау материалларын сатып алу), килешү буенча эш өчен түләү), җәйге вакытта юл буйларын чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияләрне чабу, ягулык-майлау материаллары, трактор һәм триммерлар өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (энергия саклаучы яктырткычлар, лампалар, электр товарлары сатып алу, аларны урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (насос сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (территорияләрне чабу, чүп үләннәрен һәм үсемлекләрне юк итү чаралары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуция челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында "бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru., «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, кабул ителгән көннән алып 10 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авылы, Үзәк урамы, 47 йорт мәгълүмат стендында игълан итәргә.

4. . Әлеге карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы Н. М. Илалова